ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«31» мая 2022 ел № 408

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 03 мартындагы 130 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районының административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында**

"Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы ТР Законы нигезендә һәм җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен нәтиҗәле гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 03 мартындагы 130 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районының административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертергә һәм аны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.М. Гатиятов

Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
31 мая 2022ел, № 408
карарына кушымта

**Арча муниципаль районының административ комиссиясе**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Гатиятов Ренат Мансурович | - Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Касыймов Рөстәм Фәритович | - «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары; |
| Нотфуллин Илдар Рәшитович | - Административ комиссиянең баш белгече, комиссия секретаре. |

***Комиссия әгъзалары:***

| | |
|---|---|
| Сәгыйтова Ләйсән Гарәфетдиновна | - Арча район Советы аппаратының юридик мәсьәләләр бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Билалова Гөлназ Хөрмәтулловна | - Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитетының 1 категорияле белгече (килешү буенча). |